КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 13 апрель г.Казань № 240

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Медицина күрсәткечләре нигезендә транспорт чаралары булган инвалидларга (шул исәптән инвалид балаларга) яки аларның законлы вәкилләренә, аларга түләнгән иминият премиясе компенсациясен түләү вәкаләтләрен тормышка ашыру өчен федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына субвенцияләр рәвешендә бирелә торган акчаны тоту кагыйдәләрен раслау турында» 2008 ел, 27 март, 189 нчы карары белән расланган Медицина күрсәткечләре нигезендә транспорт чаралары булган инвалидларга (шул исәптән инвалид балаларга) яки аларның законлы вәкилләренә, аларга түләнгән иминият премиясе компенсациясен түләү вәкаләтләрен тормышка ашыру өчен федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына субвенцияләр рәвешендә бирелә торган акчаны тоту кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Медицина күрсәткечләре нигезендә транспорт чаралары булган инвалидларга (шул исәптән инвалид балаларга) яки аларның законлы вәкилләренә, аларга түләнгән иминият премиясе компенсациясен түләү вәкаләтләрен тормышка ашыру өчен федераль

бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына субвенцияләр рәвешендә бирелә торган акчаны тоту кагыйдәләрен раслау турында» 2008 ел, 27 март, 189 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2009 ел, 14 гыйнвар, 10/1 нче, 2009 ел, 24 декабрь, 880 нче, 2010 ел, 27 декабрь, 1122 нче, 2011 ел, 5 декабрь, 994 нче, 2012 ел, 11 декабрь, 1078 нче, 2013 ел, 10 декабрь, 964 нче, 2014 ел, 25 декабрь, 1027 нче, 2015 ел, 21 декабрь, 962 нче, 2016 ел, 21 декабрь, 963 нче, 2017 ел, 8 июнь, 360 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Медицина күрсәткечләре нигезендә транспорт чаралары булган инвалидларга (шул исәптән инвалид балаларга) яки аларның законлы вәкилләренә, аларга түләнгән иминият премиясе компенсациясен түләү вәкаләтләрен тормышка ашыру өчен федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына субвенцияләр рәвешендә бирелә торган акчаны тоту кагыйдәләренә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3 нче пункт үз көчен югалткан дип танырга;

4 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Министрлык Казначылыктан субвенцияләрне финанслауның чик күләмнәренә җиткерергә чыгым җәдвалын алганнан соң биш эш көне эчендә Казначылыкка, алга таба компенсация алучыларның вәкаләтле банклардагы шәхси счетларына күчерү яки почта элемтәсе оешмалары аша яшәү урыны буенча алып барып бирер өчен «Республика матди ярдәм (компенсация түләүләре) үзәге» дәүләт казна учреждениесенә (алга таба – Үзәк) субвенцияләрне финанслауның чик күләмнәренә җиткерергә чыгым җәдвалын тапшыра.»;

түбәндәге эчтәлекле $4^1$ нче пункт өстәргә:

«$4^1$. Үзәк квартал саен, хисап чорыннан соң килгән айның 11еннән соңга калмый Министрлыкка Россия Федерациясе Финанс министрлыгы билгеләгән форма буенча финанслар белән тәэмин итү чыганагы субвенция булган Татарстан Республикасы бюджетының башкарылган чыгымнары турында хисап тапшыра.»;

5 нче пунктның икенче абзацында «8еннән соңга калмый» сүзләрен «13еннән соңга калмый» сүзләренә алмаштырырга;

7 нче пунктта «Министрлык» сүзеннән соң «һәм Үзәк» сүзләрен өстәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин